| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230 | Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230 |

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» август 2020 ел № 267

«Әгерҗе муниципаль районында гадәттән тыш хәл очрагында зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын булдыру турында» Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 21 февралендәге 62 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең «Вакытлыча урнаштыру пунктлары турында» 2020 елның 15 июлендәге 7552-3-2 номерлы хатын исәпкә алып, Әгерҗе муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган очракта халыкны вакытлыча күчерү чараларын тәэмин итү һәм уздыру максатларында, Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Гадәттән тыш хәл очрагында Әгерҗе муниципаль районында зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын булдыру турында» 2011 елның 21 февралендәге 62 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. 2 нче кушымта нигезендә вакытлыча урнаштыру пунктлары булдырырга.» (кушымтада бирелә).

1.2. 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. "Әгерҗе РҮХ" ДАССОның баш табибына эвакуацияләнә торган халыкка беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен вакытлыча урнаштыруның һәр пунктына медицина хезмәткәре бүлеп бирүне күздә тотарга.».

1.3. 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Вакытлыча урнаштыру пунктлары җитәкчеләренә һәм хезмәт җитәкчеләренә ПВР эшчәнлеге өчен бүлеп бирелгән көчләр һәм акчалар 2020 елның 1 октябренә кадәр шәхси состав, мөлкәт формалаштыру күрсәткечләрен тупларга һәм вакытлыча урнаштыру пункты турындагы нигезләмә таләпләре нигезендә документация әзерләргә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетынын
2020 елнын 26 августындагы
267 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының вакытлыча урнаштыру пунктлары (ПВР)

| **№** | **Учреждениенең факттагы адресы** | **Учреждение исеме** | **ПВР җитәкчесе** |
|---|---|---|---|
| 1. | 422230, Әгерже ш., Нариман ур. 27 | Әгерҗе шәһәренең «1 нче гимназия» МБМУ | Гимназия директоры |
| 2. | 422230, Әгерже ш., Гагарин ур, 56 | «2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МУ | Мәктәп директоры |
| 3. | 422230, Әгерже ш., Октябрьская, 25 | «Тажи Гыйззәт исемендәге 3 нче мәктәп» МБМУ | Мәктәп директоры |
| 4. | 422230, Әгерже ш., К.Маркс ур,7, | «4 нче мәктәп» МБМУ | Мәктәп директоры |
| 5. | 422202, Иж-Бубый, Центральная, 18 | Иж-Бубый урта мәктәбе | Мәктәп директоры |
| 6. | 422204, Тирсә, Восточная, 19 | Тирсә урта мәктәбе | Мәктәп директоры |
| 7. | 422212, Кырынды, Советская, 33 | Кырынды авыл мәдәният йорты | Авыл мәдәният йорты директоры |
| 8. | 422230, Әгерже ш., Вокзальная, 1 | ҖЧҖ «УК «СМП-184» | ҖЧҖ «УК «СМП- 184» коменданты |

___